Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

1 сентябрь, 2025 ел № 15

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Богородский авыл җирлеге, Беренче Май поселогы адресы буенча урнашкан 16:33:021127:606, 16:33:021127:630 кадастр номерлары булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлекләре формалаштыру буенча территорияне межалау проекты турында гавами тыңлаулары үткәрү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1743 нче номерлы «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» карарының 4.2 пункты, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 80 нче номерлы карары (2017 елның 14 декабрендәге 94 нче номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 нче номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156 нчы номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 62 нче номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 нче номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә гавами тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, район халкының тормыш эшчәнлеге өчен уңайлы шартларга хокукларын, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында карар бирәм:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Богородский авыл җирлеге, Беренче Май поселогы адресы буенча урнашкан 16:33:021127:606, 16:33:021127:630 кадастр номерлары булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлекләре формалаштыру буенча территорияне межалау проекты турында гавами тыңлаулары билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларын оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Башкарма комитетына җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлауларын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.
3. Гавами тыңлаулар 2025 елның 20 сентябреннән дә соңга калмыйча

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (гавамика игълан итәргә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге
башлыгы урынбасары А.Р. Саруханян